ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**28.02.2022** **г.Чистополь** **№ 142**

2022 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган һәм салым салынырга тиешле керемнең иң чик күрсәткечләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 49,51 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән иң чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы нигезендә, шулай ук «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр союзы» коммерциясез партнерлыгы турындагы 2022 елның 7 февралендәге 37 номерлы хатка нигезләнеп Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2022 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен иң чик мәгънәләрне билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары милкендәге һәм гаиләнең һәр әгъзасына салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме – 306 423 сум.

1.2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме - 7454 сум.

2. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының Торак сәясәте бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктларында күрсәтелгән күрсәткечләрне файдаланырга, гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗлар дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының Торак сәясәте бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов